КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 14 февраль г.Казань № 86

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт функцияләрен үтәү буенча административ регламентларны эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1192 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт функцияләрен үтәү буенча административ регламентларны эшләү һәм раслау тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт функцияләрен үтәү буенча административ регламентларны эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1192 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 12 февраль, 97 нче, 2014 ел, 10 июль, 484 нче, 2017 ел, 24 ноябрь, 902 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт функцияләрен үтәү буенча административ регламентларны эшләү һәм раслау тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.4 пунктның «е» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«е) «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне тормышка ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» Федераль законны бозган өчен юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең

җаваплылыгы, әлеге законның 1 статьясындагы $3^1$ өлештә каралган очраклардан тыш;»;

2.4.6, 2.4.7 пунктчаларга, 2.5 пунктның икенче абзацына «, әлеге законның 1 статьясындагы $3^1$ өлештә каралган очраклардан тыш.» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин